ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалау турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2019 елның 23 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалау турында» 2009 елның 29 октябрендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 9 – 10; 2010, № 11; 2014, № 7; 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 54 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның 2 өлешендә:
а) 2 пунктта «Наркотик чаралар турында конвенция,» сүзләрен төшереп калдырырга;
б) 8 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

2) 5 статьяның 2 өлешендә:
а) 2 пунктта «психоактив матдәләрне медицинадан тыш кулланучы затларны ачыклау өчен» сүзләрен «наркотик чараларны һәм психоактив матдәләрне законсыз куллануны башлангыч чорында ачыклау максатларында федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә» сүзләренә алмаштырырга;
б) 3 пунктта «, наркоманияне вакытыннан элек ачыклау максатларында мәгариф өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы билгеләгән» сүзләрен «башлангыч чорында ачыклау максатларында федераль законнарда билгеләнгән» сүзләренә алмаштырырга;

3) 9 статьяның 1 өлешендәге 3 пунктында «наркоманияне» сүзеннән соң «һәм токсикоманияне» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2019 ел, 16 ноябрь
№ 85-ТРЗ